

12-14 ноябрь коннәрендә Ботенроссия туган тел форумы vтте. Ботендонья татар конгрессы Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә vткәргән чарага 28 Россия регионнарыннан һәм шул исәптән Татарстаннан 800 татар теле укытучысы жыелган иде. Мордовиядән 13 делегат Форум эшендә катнашты. Программа кысаларында торле мастер-класслар, Арча муниципаль районына сәфәр, мәдәни программа һәм Татарстан Республикасы рәисе Р.Н.Миннеханов катнашында пленар утырыш каралган иде. Боларда барынсында да актив Мордовиянен торле районнарыннан мәгариф хезмәткәрләре катнашты.  Туган тел форумында Рузаевка районы Шәриф Камал исемен йорткән Татар Пешлә мәктәбе укытучысы Сания Спартак кызы Саляева, Кадошкино районы Латышовка урта мәктәбе директоры Татьяна Анатольевна Кадрякова белән Светлана Равил кызы Поташова, Ромоданово районы Белозерье мәктәбе укытучысы Айса Рәис улы Ахмяров, Алтар урта мәктәбе директоры Диана Наиль кызы Нугаева vзенен урынбасары Венера Галлям кызы Конешева белән, Лэмберә районы житәкчесе урынбасары Елена Усман кызы Громова, Мәгариф бvлеге методистлары – Эльвира Рәсим кызы Трикова, Линара Аллям кызы Муртазина, Регина Юнир кызы Тимкаева, Лэмберә районынын Кривозерье урта мәктәбе директоры Наиль Хафиз улы Янгляев белән Луиза Низаметдин кызы Смакаева, Пензятка мәктәбеннән Рауза Мокаддәс кызы Юмаева катнаштылар.

«Корстон» кунакханә сәвдә-кvнел ачу комплексында Россия тобәкләреннән килгән катнашучыларны теркәлгәч, Казан һәм Казан Кремле буйлап экскурсия иде. Экскурсия барышында форум катнашучылары Казаннын истәлекле урыннары, тарихы һәм кvренекле кешеләре турында бик кvп мәгълvмат алдылар. Форумнын беренче коне ахырында делегатлар Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәvләт драма һәм комедия театрында «Идегәй» спектаклен караганнар.

Икенче кон Тантаналы чараны Данис Шакиров ачып жибәрде. Ул делегатларны Милли Шурасы рәисе Васил Шәйхразыев исеменнән сәламләде һәм котлады.

– Ботендонья татар конгрессы тарафыннан vткәрелә торган дистәләгән проект бар. Ә Ботенроссия “Туган тел” форумы беренче тапкыр оештырыла. Бvгенге кондә без туган тел укытучыларын милли хәрәкәт вәкиле буларак кvрәбез, чонки



сез милләт баласы тәрбиялисез. Сез – безнен очен терәк! Форумнын шигаре итеп юкка гына “Тәрбия. Белем. Тел” шигаре сайланмады. 3 кон дәвамында барлык борчыган сорауларга жавап һәм анын чишелешен бергә табарбыз, дип уйлыйм. Программа туган тел укытучысына татар теле һәм әдәбиятын укыту серләрен ойрәтvгә генә тvгел, ә могаллимнен тел һәм милләт сакчысы икәнлеген раслауга юнәлтеп тозелде. Бу оештырылган ижади остаханәләрдә чагылыш табачак. Бvген без сезнен очен Ботендонья татар конгрессы Милли Шурасы тарафыннан игълан ителгән Дастаннар елы унаеннан “Идегәй” спектаклен кvрсәтәчәкбез. Дастан – ул милли vзанны

чагылдырган милли горурлык чыганагы. Форум эшендә барыгызга да зур унышлар, бәхет һәм сәламәтлек телим, – диде ул.
13 ноябрьдә делегатлар очен Арча муниципаль районындагы белем оешмаларынын эшчәнлеге белән танышканнар. Биредә татар телен уку-укытуга бәйле конvзәк мәсьәләләргә багышланган торле педагогик оста-ханәләр дә узган. Шулай ук укытучылар очен татар милли бизәкләрен тоширv, татар халык ашларын әзерләv, татар декоратив-гамәли сәнгате, татар халык биюе буенча мастер-классларыннан vзләренә материал туплап кайттылар безнен делегатлар.
14 ноябрьдә Татарстан Республикасы Рәисенен Ростәм Миннеханов катнашында форумнын пленар утырышы vтте. Шуннан сон 4 мәйданчыкта делегатлар секцияләрдә эшләделәр. Мәктәп директорлары, мәгариф бvлекләре, татар иҗтимагый vзәкләре житәкчеләре Шиһабетдин Мәржани исемендәге 2 нче татар гимназиясе эшчәнлеге белән таныштылар.
- Форум эчтәлекле vтте, оештыручыларга рәхмәтебезне белдерәбез: киләчәк эшебездә куллану очен кvп кенә материаллар туплап кайттык, ди Венера Галләм кызы Конешева.

**Наилә НАСЫРОВА**